| БАВЛИНСКИЙ ГОРОДСКОЙ СОВЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАУЛЫ ШӘҺӘРЕ СОВЕТЫ |
|---|---|

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

22.10.2021 Баулы шәһәре № 40

Татарстан Республикасы
«Баулы шәһәре» муниципаль
берәмлеге вәкаләтләренең бер
өлешен гамәлгә ашыруны
тапшыру турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы 4 өлеше, «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Баулы шәһәр Советы КАРАР ИТТЕ:

1. «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлегенең төзекләндерү өлкәсендә җирле әһәмияттәге аерым мәсьәләләрне хәл итү буенча вәкаләтләрен «Баулы муниципаль районы» муниципаль берәмлегенә тапшырырга:

- тышкы мәгълүмат чараларын урнаштыру проектын килештерү буенча;

- җир эшләрен башкаруга рөхсәт бирү буенча.

2. Әлеге карарны карау өчен Баулы муниципаль районы Советына җибәрергә.

3. «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты җитәкчесенә, Баулы муниципаль районы Советы карарын алган вакыттан алып 10 календарь көннән артмаган срокта җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү вәкаләтләрен гамәлгә ашыруны тапшыру турында килешү төзү буенча як булып катнашырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://www.pravo.tatarstan.ru) һәм Баулы муниципаль районы сайтында (http://www.bavly.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

5. Әлеге карар басылып чыкканнан соң (халыкка җиткергәннән) үз көченә керә.

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Баулы шәһәр Советының законлылык, хокук тәртибе, спорт һәм яшьләр эшләре мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Баулы шәһәре Мэры урынбасары,
шәһәр Советы Рәисе урынбасары К.Ф. Корбанов